**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.09.2026 г.Казань № 388

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына караган оешмаларда вазыйфаларга билгеләнгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле вазыйфалар исемлеген раслау турында

2008 елның 25 декабреннән «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы федераль законның 8 маддәсе, 2012 елның 03 декабреннән «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүен тикшерү турында» 230-ФЗ федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 28 февраленнән «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керә торган зат һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау турында» 137 номерлы карары нигезендә

**б о е р а м :**

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына караган оешмаларда вазыйфаларга билгеләнгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган

балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле вазыйфаларның беркетелгән исемлеген расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үз өстемдә калдырам.

Министр В.А. Леонов

РАСЛАНДЫ
Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
_______________ ______номерлы
приказы белән

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына караган оешмаларда вазыйфаларга билгеләнгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле вазыйфалар исемлеге

1) Су спорт төрләре буенча олимпия резервы «Акватика» республика спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе директоры;

2) «Батыр» олимпия резервы республика спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт автоном учреждениесе директоры;

3) «Динамо» олимпия резервы республика спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт автоном учреждениесе директоры;

4) «Стендлы һәм пуляла ату буенча олимпия резервы республика спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе директоры;

5) «Фехтование буенча олимпия резервы республика спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт автоном учреждениесе директоры;

6) «Тимераякта фигуралы шуу һәм шорт-трек буенча олимпия резервы республика спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе директоры;

7) « Р.Г. Нәҗметдинов исемендәге шахмат, шашка, го буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт автоном учреждениесе директоры;

8) «Көрәш буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт автоном учреждениесе директоры;

9) «Республика спорт-җайлашу мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе директоры;

10) «Барс» кышкы спорт төрләре буенча олимпия резервы республика спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе директоры;

11) «Ф.Г. Вәлиев исемендәге бадминтон буенча олимпия резервы республика спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе директоры;

12) «Ат спорты буенча республика спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе директоры;

13) «Регби буенча республика спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе директоры;

14) «Гольф буенча республика спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе директоры;

15) «Спорт сарае» дәүләт бюджет учреждениесе директоры;

16) «Маяк» спорт комплексы» дәүләт автоном учреждениесе директоры;

17) «Әлмәт физик культура көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры;

18) «Казан олимпия резервы училищесы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе директоры;

19) «Физик культура һәм яшүсмерләр спорты республика үзәге» дәүләт бюджет белем бирү учреждениесе директоры;

20) «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесе директоры;

21) «Универсиада авылы» Татарстан Республикасы Дәүләт автоном учреждениесе директоры.